**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июль № 466

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына агымдагы елның 1 февраленә кадәр, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып формалаштырылган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар исемлекләрен (фамилияләрен, исемнәрен һәм аталарының исемнәрен, шулай ук биләгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын күрсәтеп) Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

исемендәге «...тәртибе турында нигезләмә» сүзләрен «...тәртибе» сүзенә алмаштырырга;

1.3 нче пунктта «медицина күрсәткечләре буенча савыктыру өчен дәвалау һәм тернәкләндерү» сүзләрен «медицина тернәкләндерүе» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 нче пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендә медицина учреж-дениеләрендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә медицина оешмаларында гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «дәүләт һәм муниципаль амбулатория-поликлиника учреждениеләре» сүзләрен – «медицина оешмалары» сүзләренә, «2 нче Республика клиник хастаханәсе» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «дәүләт һәм муниципаль стационар медицина учреждениеләре» сүзләрен – «медицина оешмалары» сүзләренә, «2 нче Республика клиник хастаханәсе стационарында» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария частенда» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 нче пунктта «дәүләт һәм муниципаль амбулатория-поликлиника учреждениеләрендә» сүзләрен – «медицина оешмаларында» сүзләренә, «Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 нчы пунктта «көндезге уку формасындагы урта яки югары һөнәри белем бирү учреждениеләренең 23 яшькәчә студентлары» сүзләрен «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда, шул исәптән, әгәр укырга җибәрү Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә башкарылса, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил оешмаларында төп мәгариф программалары буенча көндезге формада укый торган балалары, алар әлеге укуны тәмамлаганчы, әмма 23 яшькә җиткәнгә кадәр генә» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 нче пунктта «2 нче Республика клиник хастаханәсе» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария часте» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 нче пунктта «2 нче Республика клиник хастаханәсендә» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария частенда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\466.doc